ГЛАВА АЗАЛАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЗАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

2024 ел , 1 ноябрь. — № 6

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Юлтимер авылы гражданнарының 2025 елда узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-РТЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 12 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Юлтимер авылы, Елга урамы, 5 йорты адресы буенча урнашкан Юлтимер авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсәләләрне түбәндәгечә расларга:

“I нче группа инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәренән, көндезге бүлек студентларынан, хәрби хезмәт һәм контракт буенча узучы хезмәткәрләрдән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Азалак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән 2025 елда 500 сум узара салым җыярга һәм күләмендә кертергә, шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тоторга Сез ризамы:

1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- Юлтимер авылы урамнарнарын яктырту объектларын карап тоту һәм яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

2. Юлтимер торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- ГАЗ-САЗ-3512 автомашиналары һәм Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- Беларусь МТЗ-82.1 тракторына , ГАЗ-САЗ-3512 автомашиналары өчен запас частьләр сатып алу;
- Юлтимер авылында Яңа, Тау, Яр буе,Үзәк, урамы буенча юлларны ремонтлау ( махсус техника арендалау, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, таш ташу һәм вак таш җәю, юл өслеген тигезләү).
3. Торак пункт территориясен төзекләндерү:
- Юлтимер авылы территорияләрен җәй көне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу.
4. Санкциясез чүплекләрне бетерү:
- Юлтимер авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп чар җыелу урыннарын чистарту (махсус техника арендалау, килешү буенча эшләр өчен түләү);

"ӘЙЕ" "ЮК?"

3. Әлеге карарны 7 көн эчендә Азалак авылы территориясендә урнашкан махсус мәгүлүмәти стентларда урнаштырырга, «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, https://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

РТ Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге башлыгы: И.Г.Габдулгазизов